ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАДЫБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАДЫБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

03.02.2023 Кадыбаш авылы № 8

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлегендә нотариаль гамәлләр башкару буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында» 25.10.2019 елның 13 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлегендә нотариаль гамәлләр башкару буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында» 25.10.2019 елның 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- 1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 1.13 пунктча өстәргә:

«1.13. нотариаль расланган килешүләрнең эчтәлеген белдерүче документларның дубликатларын бирү.".

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында веб-адрес буенча урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 11.01.2023 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Х.Л.Закиров